| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**08.05.2018** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1041** |

Күп фатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешманы сайлап алу буенча конкурс комиссиясе төзү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 161 ст. 4 нче пунктында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күп фатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешма сайлап алу буенча ачык конкурс уздыру тәртибе турында» 2006 елның 06 февралендәге 75 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Күп фатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешма сайлап алу буенча конкурс комиссиясе төзергә һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).
2. «Күп фатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешманы сайлап алу буенча конкурс комиссиясе турында» нигезләмәне (2 нче кушымта) расларга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Күп фатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешма сайлап алу буенча конкурс комиссиясе төзү турында» 2015 елның 21 апрелендәге 877 номерлы, «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Күп фатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешманы сайлау буенча конкурс комиссиясе төзү турында» 2015 елның 21 апрелендәге 877 номерлы карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында»2016 елның 2 мартындагы 456 номерлы карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 8 маендагы
1041 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Күп фатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешманы сайлап алу буенча конкурс комиссиясе составы**

**<u>Комиссия рәисе:</u>**

А.Х. Сәхибуллин - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;

**<u>Комиссия рәисе урынбасары:</u>**

Р.А. Гыйрфанов - «ТР ЗМР Торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты» МБУ җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы;

**<u>Комиссия секретаре:</u>**

А.Е. Артамонова - «ТР Торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты» МБУ күп фатирлы йортлар идарәчеләре белән капиталь ремонт һәм хезмәттәшлек бүлегенең баш белгече.

**<u>Комиссия әгъзалары</u>**:

Н.В. Гусев - «ЗМР мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ җитәкчесе (килешү буенча);

В.Б. Макеев - Зеленодольск шәһәренең 4 нче сайлау округы депутаты (килешү буенча);

В.В. Братухин - Зеленодольск шәһәренең 7 нче сайлау округы депутаты (килешү буенча).

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 8 маендагы
1041 номерлы карарына
2 нче кушымта

Күп фатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешманы сайлап алу буенча конкурс комиссиясе турында
нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә гамәлдәге законнар нигезендә эшләнгән һәм конкурс комиссиясенең күп фатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешманы сайлау буенча ачык конкурс уздыру эшен регламентлаштыра торган мәсьәләләрне билгели (алга таба - Конкурс комиссиясе).

1.2. Конкурс комиссиясе үз эшендә Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күп фатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешманы, муниципаль хокукый актларны һәм әлеге Нигезләмәне сайлау буенча ачык конкурс уздыру тәртибе турында» 2006 елның 06 февралендәге 75 номерлы карарына, муниципаль хокукый актларга һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Әлеге Нигезләмә белән җайга салынмаган конкурс уздыру мәсьәләләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күп фатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешманы сайлау буенча җирле үзидарә органы тарафыннан ачык конкурс уздыру тәртибе турында» 2006 елның 06 февралендәге 75 номерлы карары нигезендә хәл ителә.

## 2. Конкурс комиссиясенең төп бурычлары

2.1. Конкурс комиссиясенең төп бурычлары түбәндәгеләр:

- конкурста катнашуга заявкаларны карау һәм дәгъвачыларның конкурс документациясендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерү;
- конкурс уздыру.

## 3. Конкурс комиссиясенең эш тәртибе

3.1. Конкурс комиссиясе җитәкчелеген Конкурс комиссиясе рәисе, ә ул булмаганда - Конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан билгеләп куелган урынбасары башкара.

3.2. Конкурс комиссиясе, әгәр утырышта әгъзаларының гомуми санының 50 проценттан артыгы катнашса, хокуклы. Конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы 1 тавышка ия.

3.3. Конкурс комиссиясе карарлары утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда карар Конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан кабул ителә.

3.4. Конкурс комиссиясе карары кабул ителгән көнне утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары имзалаган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

3.5. Конкурс комиссиясе утырышларында торак милекчеләре ширкәтләренең, торак, торак-төзелеш кооперативларының яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларының, күп фатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре ассоциацияләренең, шулай ук кулланучылар берләшмәләренең (аларның ассоциацияләре, берлекләре) вәкилләре катнаша ала. Күрсәтелгән вәкилләрнең вәкаләтләре документаль рәвештә раслана.

3.6. Конкурс комиссиясе утырышларында дәгъвачылар, конкурста катнашучылар яисә аларның вәкилләре, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

## 4. Конкурс комиссиясенең җаваплылыгы

4.1. Конкурс комиссиясе әгъзалары гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә җаваплылык тоталар.